КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 май г.Казань № 636

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлында сул борылыш юлын һәм борылыш элмәкләрен төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII1 бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм $28^1$ статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында төбәк әһәмиятендәге «Казан – Шәмәрдән» автомобиль юлында сул борылыш юлын һәм борылыш элмәкләрен төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен юридик затлар милкендә һәм арендасында (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе һәм арендаторы) булган, кушымтада күрсәтелгән 29 034 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

Алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан 16:33:181614:1035 кадастр номерлы «Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлында сул борылыш юлын һәм борылыш элмәкләрен төзү» күчемсез мөлкәт объекты алынмаска тиеш дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә һәм арендаторларына, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алына торган җир кишәрлеген алу турында килешү, түләтелә торган җир кишәрлегенә аренда шартнамәсен туктату турында килешү (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә һәм арендаторына җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләре милекчесе һәм арендаторы тарафыннан имзаланган килешүләр законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлында сул борылыш юлын һәм борылыш элмәкләрен төзү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын раслау турында» 2019 елның 17 маендагы 772 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 25 май, 636 нчы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Җир кишәрлегенең гомуми мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекче/арендалаучы |
|---|---|---|---|---|
| 16:33:080515:228 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шигали авыл җирлеге | 30 055 | 149 | «Лэнд Девелопмент» ябык катнаш пай инвестиция фонды |
| 16:33:181614:690 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шигали авыл җирлеге | 45 716 | 28 885 | «Питрәч районы агрохимсервисы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| Барлыгы | | 75 771 | 29 034 | |

___